ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 17 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарә органнары) муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) бирүгә бәйле мөнәсәбәтләрне җайга сала.

2 статья. **Җирле үзидарә органнарына бирелә торган дәүләт вәкаләтләре**

1. Җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча дәүләт вәкаләтләре бирелә.

2. Җирлекләрдән кергән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат дигәндә, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында»

2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясында күрсәтелгән мәгълүмат аңлашыла.

3 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре исемнәре**

Дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасының түбәндәге муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына бирелә:

Әгерҗе муниципаль районы, Азнакай муниципаль районы, Аксубай муниципаль районы, Актаныш муниципаль районы, Алексеевск муниципаль районы, Әлки муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Апас муниципаль районы, Арча муниципаль районы, Әтнә муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Балтач муниципаль районы, Бөгелмә муниципаль районы, Буа муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Чүпрәле муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зәй муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Кайбыч муниципаль районы, Кама Тамагы муниципаль районы, Кукмара муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Лениногорск муниципаль районы, Мамадыш муниципаль районы, Менделеевск муниципаль районы, Минзәлә муниципаль районы, Мөслим муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Яңа Чишмә муниципаль районы, Нурлат муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Саба муниципаль районы, Сарман муниципаль районы, Спас муниципаль районы, Тәтеш муниципаль районы, Тукай муниципаль районы, Теләче муниципаль районы, Чирмешән муниципаль районы, Чистай муниципаль районы, Ютазы муниципаль районы.

4 статья. **Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре бирелә торган вакыт**

Җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләре чикләнмәгән вакытка бирелә.

5 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең

гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару методикасы нигезендә әлеге Законга кушымта буенча башкарыла.

3. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләме чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.

6 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла торган матди чаралар**

1. Татарстан Республикасы милкендәге матди чаралар әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү кирәк булганда, тапшырыла торган матди чаралар исемлеге нигезендә җирле үзидарә органнарына түләүсез файдалануга тапшырыла.

2. Тапшырыла торган матди чаралар исемлеген әзерләү, раслау һәм матди чараларны тапшыру турында карар кабул итү Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органының җирле үзидарә органнары тәкъдимнәрен исәпкә алып әзерләнгән мөрәҗәгате нигезендә башкарыла.

7 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда җирле үзидарә органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенә бәйле эшчәнлекне камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрергә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм алырга;

3) муниципаль берәмлекнең уставында каралган очракларда һәм тәртиптә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан файдаланырга;

4) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар чыгарырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләргә;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органына «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда мәгълүмат бирергә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләрен үтәргә;

4) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган матди чараларның исәбен алып барырга һәм алардан тиешлечә файдалануны тәэмин итәргә;

5) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларыннан максатчан билгеләнештә файдаланырга;

6) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органына квартал саен дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар тапшырырга;

7) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкаруда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына кирәкле ярдәм күрсәтергә;

8) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру туктатылган очракта файдаланылмаган финанс чараларын, шулай ук матди чараларны кайтарырга.

8 статья. **Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының хокуклары һәм бурычлары**

1. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләргә хокуклы:

1) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында җирле үзидарә органнары һәм (яисә) аларның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозуларны бетерү, шул исәптән әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү буенча язма күрсәтмәләр бирергә;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне гамәлгә ашырырга;

3) дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документлар, мәгълүмат һәм материаллар соратып алырга.

2. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

1) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрен карарга;

2) җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруларын тикшереп торуны башкарырга;

3) җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларга мәгълүмати, консультатив, оештыру һәм методик ярдәм күрсәтергә.

9 статья. **Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында җирле үзидарә органнарының хисап бирү тәртибе**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында хисаплар җирле үзидарә органнары тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән рәвештә квартал саен хисап кварталы тәмамланганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла, моңа дүртенче квартал өчен хисаплылык керми, ул хисап чорыннан соң килә торган елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

10 статья. **Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору**

Җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тору түбәндәгечә башкарыла:

1) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан – җирле үзидарә органнарының тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырулары өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

в) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнар таләпләрен бозуларны бетерү буенча мәҗбүри үтәлергә тиешле язма күрсәтмәләр бирү;

2) Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

3) Татарстан Республикасы милкендәге матди чараларны әлеге Законда каралган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен җирле үзидарә

органнарына түләүсез файдалануга тапшырган очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан – җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган дәүләт мөлкәтен саклау һәм тиешенчә куллану өлешендә, түбәндәге юллар белән:

а) дәүләт вәкаләтләрен башкару турында кирәкле документларны, хисапларны һәм мәгълүматны соратып алу;

б) Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары нигезендә җирле үзидарә органнарының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлеген урыннарга чыгып тикшерү;

в) бозуларны бетерү һәм аларны булдырмау буенча кирәкле чаралар күрү.

11 статья. **Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату шартлары һәм тәртибе**

1. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату түбәндәге очракларда Татарстан Республикасы законы белән башкарыла:

1) җирле үзидарә органнары тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җайга салу өлкәсендәге законнар таләпләрен үтәмәгәндә яисә тиешенчә үтәмәгәндә;

2) җирле үзидарә органнары һәм (яисә) аларның вазыйфаи затлары әлеге Закон таләпләрен бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрне үтәмәгәндә;

3) федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен үтәү мөмкинлеген юкка чыгарырлык итеп үзгәртелгәндә.

2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын һәм матди чараларны кайтаруны таләп итә.

3. Җирле үзидарә органнары дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча законнар таләпләрен үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы күрсәтелгән хокук бозулар ачыклангannan соң 10 көн эчендә җирле үзидарә органнарына аларны бетерү турында күрсәтмә җибәрәләр.

4. Ачыкланган хокук бозуларны бетерү турындагы күрсәтмә җирле үзидарә органына кергән көненнән алып ун көннән дә соңга калмыйча мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш. Күрсәтмәне карау нәтиҗәләре хакында мондый күрсәтмәне җибәргән органга кичекмәстән язма рәвештә хәбәр ителә.

5. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару өлкәсендәге вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең финанс сәясәте өлкәсендәге

вәкаләтле органы, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы үз компетенцияләре нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны туктату турында тәкъдимнәр һәм тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертәләр.

12 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары әлеге Закон үз көченә кергән көннән алып өч ай эчендә аңа туры китерелергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН / ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казан,Кремль
2015 елның 3 ноябре
№ 92-ТРЗ

“Татарстан Республикасы муниципаль районнарының
җирле үзидарә органнарына муниципаль районга
керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы
муниципаль норматив хокукый актлары
регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат
җыю буенча Татарстан Республикасының
дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен билгеләү өчен нормативларны исәпләп чыгару
методикасы

Әлеге Методика муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен (алга таба – дәүләт вәкаләтләре) гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль районнар бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләмен исәпләп чыгару өчен билгеләнә.

*I*-муниципаль районына субвенция күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = O_i : V \times R \times K_i,$$

монда:

$S_i$ – i-муниципаль районы бюджетына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен субвенция күләме;

$O_i$ – $i$-муниципаль районында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алып (бер елга исәпләгәндә), дәүләт вәкаләтләрен башкаручы белгечкә тулаем акчалата түләүне бирү чыгымнары;

$V$ – план елына производство календаре белән билгеләнгән эш вакыты, сәгать;

$R$ – бер җирлектән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүматны алуга һәм эшкәртүгә вакыт нормасы, бер елга сәгать (1 сәгать күләмендә билгеләнә);

$K_i$ – $i$-муниципаль районындагы җирлекләр саны.

Дәүләт вәкаләтләрен башкаручы белгечкә тулаем акчалата түләүне бирү чыгымнары түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$O_i = (Z_i + N_i) \times 12,$$

монда:

$Z_i$ – $i$-муниципаль районын хезмәт өчен түләү төркеменә кертүне исәпкә алып, $i$-муниципаль районы башкарма комитетының (башкарма комитеты аппаратының) I категория белгече вазыйфасы дәрәҗәсендә билгеләнә торган айлык акчалата түләү күләме;

$N_i$ – хисап чорына хезмәт хакына карата түләүләр.

Татарстан Республикасының тапшырылган дәүләт вәкаләтләре гамәлгә ашырылганда хезмәт хакына карата түләүләр чыгымнары исәбенә эш бирүче тарафыннан федераль законнар нигезендә федераль бюджетка, Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетына, Россия Федерациясе Социаль иминият фонды бюджетына (производстводагы бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминләштерү кертемнәрен кертеп), Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды һәм территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына күчерелә торган хезмәт хакына карата түләүләр керә.

Хезмәт хакына карата түләүләр түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N_i = Zj \times F,$$

монда:

$F$ – хезмәт хакына карата түләүләрнең ставкасы.